# СПАС РАЙОНЫ ЯМБАКТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕН ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 31 октябре № 2

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районының Ямбакты авыл җирлегенең
Ямбакты торак пунктында 2026 елда
гражданнарга үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең Ямбакты торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кабул итте:

1.2026 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең Ямбакты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- Ямбакты торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампалары сатып алу) ремонтлау;
- Ямбакты торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча килешү буенча эшләр һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү) ;
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү ремонт, коймалар кору, (Ямбакты торак пунктынын 1 һәм 2 нче зиратларны төзекләндерү буенча килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (чүп үләннәреннән, куаклардан чистарту, территорияне чабу) (ТРИММЕРЛАР һәм бензопилалар өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу));
- Ямбакты торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, бензин пычкылары һәм триммерлар өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү (территорияне чабу, карны чистарту);
- Ямбакты торак пунктынын яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту («Бэби » күлен чистарту), (транспорт хезмәтләре өчен түләү, эшләр өчен килешү буенча түләү));
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Кооператив урамында автомобиль юлын төзү), (транспорт хезмәтләре өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Ямбакты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:// spasskiy.tatarstan.ru) хэм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Спас муниципаль районының
Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И.Ә. Галәветдинов.